ГЛАВА ШУБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 25» июля 2019 г. № 2

**Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урын бирү һәм җиһазлау турында**

Татарстан Республикасы Сайлау Кодексының 64 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауда сайлау алды басма агитация материалларын урнаштыру өчен, һәр сайлау участогы территориясендә махсус урыннар бүлеп бирү һәм урнаштыру турында Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итү турында» гы 10 июль 2019 ел 67/516 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башлыгы карар бирә:

1. Сайлау участогы территориясендә басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урын бирергә һәм җиһазларга 1 кушымта нигезендә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге башкарма комитетына кушымта нигезендә басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен сайлау участогы территориясендә махсус урын булдырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мөҗипов.

Шубан авыл җирлеге башлыгы
карарына кушымта
"2019 елның 25 июле" № 2

## Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар исемлеге

| Сайлау участогы номеры | Басма сайлау алды агитация материалларын урнаштыру өчен махсус урыннар адресы | Элү урыны исеме (махсус җиһазландырылган конструкция, мәгълүмат стенды (реклама щиты, тумба), бина диварында, фойеда һәм тд.) |
|---|---|---|
| 1081 | Югары Шубан авылы, Үзәк урам. | мәгълүмат стенды ( 15 номерлы кибет бинасы белән 17 номерлы йорт арасында) |
| 1082 | Ярак-Чурма авылы, М.Горький урамы | мәгълүмат стенды ( 11 номерлы йорт белән 17 номерлы йорт арасында) |